# Эшне башкарды:

Казан шәһәре 9нчы номерлы гимназиясе нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Абитова Язилә Сәлим кызы

Кайда хезмәт,
шунда
хөрмәт.

**1. Нәрсә ул кушма җөмлә?**

а) берничә гади җөмләдән торган җөмлә; б) бер генә җөмләдән тора.

**2. Кушма җөмлә төрләре:**

б) иярченле кушма җөмлә; н)тезмә һәм иярченле кушма җөмлә.

**3. Тезмә кушма җөмләләрне бәйләүче чаралар:**

а) тезүче теркәгечләр; б) ияртүче теркәгечләр.

**4. Нинди җөмләләргә иярченле кушма җөмлә диләр?**

м) үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмләгә;

н) гади җөмләләрне интонация ярдәмендә бәйләнгән кушма җөмләгә;

л) үзара ияртү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмләгә.

**5. Иярчен җөмлә -**

л) иярченле кушма җөмләнең беренче җөмләсе;

и) ияреп килгән һәм баш җөмләдән чыгып куелган сорауга җавап булып килгән җөмлә;

с) иярченле кушма җөмләнең баш җөмләсе.

**6. Иярчен җөмләләрнең мәгънә ягыннан ничә төре бар?**

е) 14; т) 12; а) 10.

**7. Баш һәм иярчен җөмләләрне ничек билгелиләр?**

л) иярченле кушма җөмләдә урнашу тәртибенә карап;

и) сорау куеп; ф) интонациягә карап.

**8. ”Нинди эш уңайлы, шул эшне башкара ул” җөмләсенә кайсы характеристика туры килә?**

с) синтетик иярчен җөмләле кушма җөмлә;

к)аналитик иярчен җөмләле кушма җөмлә;

**9. Төзелеше буенча иярчен җөмләләрнең нинди төрләре бар?**

в) синтетик; ж) аналитик һәм синтетик,

**10. Аналитик бәйләүче чараларга нәрсәләр керә?**

ә) көттерү паузасы, ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр,тезүче теркәгечләр;

ө) көттерү паузасы, ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр, ияртүче теркәгечләр

ө) көттерү паузасы, ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр, ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр,

**11. Нинди иярчен җөмлә синтетик дип атала?**

д) баш җөмләгә үзенең хәбәре составында тормый торган чаралар ярдәмендә ияргән җөмлә,

р) баш җөмләгә көттерү интонациясе ярдәмендә ияргән җөмлә,

м) баш җөмләгә үзенең хәбәре составындагы чаралар ярдәмендә ияргән җөмлә,

**12. . “ Һәркемгә мәгълүм ки, илне хуҗасызлык тарката”**

л) аналитик иярчен кушма җөмлә, к) синтетик иярчен кушма җөмлә

**13 “*Кем намус белән эшли, котлаулар шуңа*” җөмләсенең төре:**

ә) аналитик иярчен кушма җөмлә, к) синтетик иярчен кушма җөмлә

# Аналитик иярчен җөмләләрдә тыныш билгеләре.

1. Кайда хезмәт , шунда хөрмәт.
2. Ялкау кешегә бу тормышта яшәү авыр , чөнки ул эш сөйми.
3. Һәркемгә мәгълүм ки , кеше күрке – хезмәт.
4. Алсу бар эшне эшләргә өлгергән, әйтерсең хуҗа-бикә.

# Көттеру паузас

Һәркемгә мәгълүм : һөнәр кешене кеше итә.

Минем дусларым тырыш, мин шуңа горурланам.

Без <u>шуны</u> истән чыгармыйк<u>:</u> хезмәт кешене кеше итә.

# Карточка №1

- Кем намус белән хезмәт итә   шул хөрмәткә ия.
- Мәгълүм ки  алма агачыннан ерак төшми.
- Бездә закон шундый  ялкауга юл ябык.
- Барыбызга да ачык  хезмәт кешене кеше  итә.

# Карточка №2

- Кайда эш җиренә җиткерелеп башкарыла шунда нәтиҗәсе күренә.
- Билгеле ки ялкауның эше бармый.
- Кем намус белән хезмәт итә шул хөрмәткә ия.
- Билгеле маңгай тиресе эшнең сыйфатын яхшырта .

# Мәкальләрне дәвам ит:

- Кем эшләми, ... .
- Агачны кем утырта, ... .
- Кем кол кебек эшли, ... .
- Кем башлый, ... .
- Кайда яхшы эш, ... .
- Кем хезмәт итми, ... .

# Бирем.

## Түбәндәге схемаларга җөмләләр төзергә.

- **[ки] , ( ) .**
- **(Кем), [шул ] .**
- **[ шул] : ( ).**
- **( Кем),** [ шуңа].

# Текст

# Һөнәр сайлау - шәхси эш.

Җир йөзенә кеше хезмәт итәргә килә. Хезмәт белән бәйле тормыштан ул ямь табып яши. Хезмәтнең әһәмияте шунда: ул кешене кеше итә, яшәвенә  мәгънә, көч бирә.

Үзенең күңеленә ошаган һөнәрне һәркем сайларга хокуклы. "Кайда хезмәт , шунда хөрмәт" – дип , халык юкка гына әйтмәгән. Ул үзенең сайлаган һөнәре белән халыкка хезмәт итә, яшәвен мәңгеләштерә.

Барыбызга да билгеле : һөнәр сайлау һәркемнең шәхси эше. Һөнәр сайлаганда шуны истән чыгармаска кирәк : һәр кеше үз мөмкинлеген яхшы белергә тиеш. Холкыңны һәм белемне дә истән чыгармаска кирәк. Белем булган җирдә хезмәтнең нәтиҗәсе күренә

# *<u>Өйгә эш.</u>*

“Мин үскәч кем булырга телим” темасына инша язарга, эшегезне аналитик һәм синтетик җөмләләр белән баетырга.

Дуслар, тагын сезгә
Бар әйтәсе бер сүзем:
Нинди һөнәр сайласаң да
Кирәк беренче белем.